Боек Ватан сугышынын дәһшәтле һәм фажигале коннәре елдан-ел ераклаша бара. Сугышта 27 миллионнан артык совет кешесе һәлак булды, дистәләргә миллион хатын-кызлар - тол, бик кvп балалар ятим калды. Илебез ярым жимерек хәлгә килде, халкыбыз кvпме кайгы-хәсрәт кичерде!?

Боек Ватан сугышында катнашкан һәрбер исем артында кеше язмышы, кеше гомере. Анда барысы да бар – шатлык һәм кайгы, ярату һәм саубуллашу, авырлыклар һәм жинv. Торле буын кешеләрен, торле милләт, һонәр, сәләтләре, шогыльләре торле булуга карамастан, аларны һәммәсен туган туфрагын, Ватанын ярату хисе берләштергән. Бу хис батырлыкка алып барган, бу хисне алар киләчәк буынга васыят итеп калдырганнар. Еллар vтv белән Ватанны ярату хисе кискенрәк тоела; батырларнын исемнәре онытылмый. Һәрбер гаиләнен Боек Ватан сугышындагы жинvгә керткән vз олеше бар. Хәтердә мәнге – исемнәр, исемнәр...vлемсезлеккә киткән исемнәр. Боек Жинv очен гомерләрен салган кешеләр. Мәрмәр ташларга уеп язылган исемнәр. Еллар vткә саен сугыш ветераннары кими бара. Кызганычка каршы, бvгенгә Дубенка районы Ломат авылында, Торбеево районы Татар Йонә авылында, Темников районы Тархан авылында, Ләмберә районы Черемиш авылында һәм башкаларында бер ветеран да исән калмаган инде. Боек Ватан сугышында һәлак булганнарга авыл уртасында обелисклар куелган. Ел саен авылдашларын горурланып якташлары искә алалар. Исәннәрен бертекләп барлыйлар, алар турында онытмый гына сойлиләр. Сvз аларнын берничәсе турында булыр.

Ләмберә районында барлыгы ундvрт Боек Ватан сугышы ветераны яши. Шербак авылында гомер итvче *Асаинов Вәлиулла Нәvмәтулла улы* шуларнын берсе. Бvген ул 94 яшен тутырган хормәтле авыл мулласы. Гомере дәһшәтле вакыйгаларны сыйдырган анын. Ин ачысы – Боек Ватан сугышы. 1942нче елнын 10 июнендә Ләмберә педагогия училищесын тәмамламаган яшvсмер Советлар Армиясе сафына чакырыла. Шулай бер айлык курслардан сон фронтка, каты сугыш кырына, кvрше Пензятка якташылары Ильяс һәм Исхак белән Ржев шәһәренә, вакытлыча корылган йозмә кvпер-понтон батальонына әләгәләр. Беренче тапкыр Днепр очен корәшә Вәлиулла Нәvмәтулла улы.

[redacted]ау

[redacted]а